МИРАС

Сабыйга

3·4
2000

Признан победителем и награжден грантом "Фонда Сороса"

НА ТАТАРСКОМ И РУССКОМ ЯЗЫКАХ



Сабыйга

№ 3-4 (69-70)—2000 ел.
(март-апрель)

Балаларның
әдәби-нәфис журналы

ОЕШТЫРУЧЫЛАР:

«Сабыйга» журналы редакциясе хезмәт коллективы, Казан шәһәр хакимияте, «Мирас» журналы редакциясе, Татарстан белем министрлыгы

Баш мөхәррир
МИҢНӘХМӘТ СӘХАПОВ

Редакция советы

Алла Айсина
Фаил Әхмәдиев
Мәхмүт Әхмәтҗанов
Шәүкәт Галиев
Мөнәвир Галимуллин
Фердинанд Галәмиев
Айрат Зарипов
Фирдәвес Зарифуллин
Фәрит Ишмаков
Хәлиф Курбатов
Аркадий Мельников
Роберт Миңнуллин
Флүн Мусин
Лилия Сәхапова
Фарис Харисов
Вахит Хаков
Зөфәр Хәкимов
Рәүф Хөснетдинов

Тышлыкта
Светлана Ибрагимова рәсемнәре.

«Сабыйга» балалар журналының индексы — **73954.** Аңа Татарстан Республикасының,Русия Федерациясе составында булган республикаларның, край һәм өлкәләрнең, БДБ составына кергән дәүләтләрнең һәм чит илләрнең элемтә бүлекләрендә чикләнмәгән күләмдә язылырга мөмкин. Журнал татар һәм урыс телләрендә нәшер ителә. Редакциянең адресы: 420066; Казан шәһәре,Чистай урамы,5 йорт. Бәйләнешкә керү өчен телефон: ***(8432)* 49-35-54.** Журналга язылу һәм аны тарату мәсьәләләре буенча 38-59-78 номерлы телефон аша мөрәҗәгать итәргә,ә басманың сыйфатына кагылышлы дәгъваларны исә 49-36-62 номерлы телефон ярдәмендә белдерергә мөмкин. Иганәчеләр өчен журналның исәп-хисап саны **р/с № 40603810562260100025**, Россия Саклык банкының Татарстан Банкы 6672/0253. Корр. счеты **№ 30101810600000000603**. Журнал идеясенең һәм исеменең авторы М. Җ. Сәхапов.

«Сабыйга» журналы Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 314 сан белән теркәлде. 1994 елның 1 июленнән бирле нәшер ителә.

Производствога бирелде 2.02.2000 ел. Басарга кул куелды 13.04.2000 ел. Форматы $84 \times 108^{1}/_{16}$. Күләме 2,0(2,1) басма табак. 3,36 нәшер-хисап табак. Офсет ысулы белән басыла. Тиражы 5700 данә. Заказ Э-67. Ваклап сатуда иреклe бәя.

«Идел-Пресс» дәүләт унитар предприятиесенең полиграфия-нәшрият комплексы. 420066; Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт.

© “Сабыйга”,2000 ел.

ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ

МАРТ

МАРТ ҖЫЛЫСЫ БЕЛӘН ҮЗЕНӘ ТАРТА.
МАРТ-ТАМЧЫ КИЛӘ, Ә КЫШ ИСӘ ЕЛЫЙ.
ТУРГАЙ ЯЗГА ФАТИХАСЫН БИРДЕ.

АПРЕЛЬ

АПРЕЛЬ — ТЕРЕ СУ АЕ.
АПРЕЛЬ — КОШ АЕ.
АПРЕЛЬ ЧӘЧӘГЕ БОЗНЫ ТИШӘ.

ВРЕМЕНА ГОДА

МАРТ

МАРТ ТЕПЛОМ ВСЕХ ПРИВЛЕКАЕТ.
ПРИДЕТ МАРТ-КАПЕЛЬНИК —
И ЗИМА ЗАПЛАЧЕТ.
ЖАВОРОНОК ВЕСНУ БЛАГОСЛОВИЛ.

АПРЕЛЬ

АПРЕЛЬ — МЕСЯЦ ЖИВОЙ ВОДЫ.
АПРЕЛЬ — ПТИЧИЙ МЕСЯЦ.
АПРЕЛЬСКИЙ ЦВЕТОК ЛОМАЕТ ЛЕДОК.

Рәссам АЛЛА АЙСИНА — *Художник АЛЛА АЙСИНА*

Сабыйга

№ 3-4 (69-70)—2000 г.
(март-апрель)

Детский литературно-художественный журнал

УЧРЕДИТЕЛИ:

Трудовой коллектив редакции журнала «Сабыйга», администрация г. Казани, редакция журнала «Мирас», Министерство образования Татарстана

Главный редактор
МИНАХМЕТ САХАПОВ

Совет редакции:

Алла Айсина
Фаил Ахмадиев
Махмут Ахметзянов
Шаукат Галиев
Мунавир Галимуллин
Фердинанд Галямиев
Айрат Зарипов
Фирдаус Зарифуллин
Фарид Ишмаков
Халиф Курбатов
Аркадий Мельников
Роберт Миннуллин
Флюн Мусин
Лилия Сахапова
Фарис Харисов
Вахит Хаков
Зуфар Хакимов
Рауф Хуснутдинов

На обложке рисунки Светланы Ибрагимовой.

Индекс детского журнала «Сабыйга» — **73954.** Подписка на журнал производится без каких-либо ограничений во всех отделениях связи Республики Татарстан, в областях, краях, республиках Российской Федерации, в государствах Ближнего и Дальнего Зарубежья. Журнал выходит на татарском и русском языках. Адрес редакции: 420066; г. Казань, ул. Чистопольская, 5; а/я № 227. Тел.: ***(8432)* 49-35-54**. По вопросам доставки и подписки обращаться по телефону: 38-59-78, качества печати 49-36-62. Для спонсоров журнала: **р/с № 40603810562260100025** в Банке Татарстан Сбербанка России 6672/0253. **Корр. счет № 30101810600000000603** в РКЦ НБ РТ, БИК 049205603. ИНН № 1654002150. Код ОКОНХ — 87100, код ОКПО — 12986213. Автор идеи и названия журнала М. Ж. Сахапов.

Журнал "Сабыйга" зарегистрирован в Мининформпечати РТ. Свидетельство № 314. Выходит с 1 июля 1994 года.

Сдано в производство 2.02.2000 г. Подписано в печать 13.04.2000 г. Формат $84 \times 108^1/_{16}$. Объем 2,0 (2,1) п.л. Учетн.-изд. л. 3,36. Печатается офсетным способом. Тираж 5700 экз. Заказ Э-67. Цена договорная.

ГУП ПИК «Идел-Пресс». 420066; г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© "Сабыйга", 2000 г.



Габдулла Тукай

ЯҢГЫР ИЛӘ КОЯШ

КОЯШ ӘЙТТЕ: «ҺАМАН МИН ЯКТЫРЫРМЫН
ВӘ БЕР ДӘ БАТМАМЫН, ЯНЫП ТОРЫРМЫН».

ДИДЕ ЯҢГЫР ДА: «ҺӘР КӨННЕ ЯВАРМЫН,
КАРА ҖИРНЕ ЮЕШЛӘР, ЕЛГАЛАРМЫН».

КОЯШ КАРШЫ ДИДЕ: «СИН БИК ЮЕШЛЕ,
ЯВАСЫҢ БЫЛЧЫРАТЫП ҺӘММӘ ТӨШНЕ.

СУЫҢНАН АНДА БАТКАК, МОНДА БАТКАК,—
СИНЕҢ БАР БЕЛГӘНЕҢ ҖИР БЫЛЧЫРАТМАК.

ЮЕШЛЕКТӘН ИГЕН, АШЛЫК ЧЕРИДЕР,
МУЖИКЛАР, ЯУМАСАЙДЕ, ДИП, ТЕЛИДЕР».

ДИДЕ ЯҢГЫР ҖАВАПТА: «СИН КЫЗАСЫҢ,
ИГЕННЕ ЯНДЫРАСЫҢ ҺӘМ КЫРАСЫҢ».

АЧУЛАНДЫ КОЯШ БУ СҮЗГӘ, КЫЗДЫ,
АЧУДАН ЭССЕЛЕКТӘ ХӘДТӘН УЗДЫ.

ДИДЕ: «МИН БИТ ҖИМЕШЛӘРНЕ ПЕШЕРГӘН,
НУРЫМНАН ҖАНЛЫ-ҖАНСЫЗ ФАЙДА КҮРГӘН».

ДИДЕ ЯҢГЫР: «АЛАРНЫ СИН ПЕШЕРСӘҢ,
Ә МИН БИТ ҮСТЕРӘМ ҺӘМ СУ ЭЧЕРТӘМ.

ӘГӘР МИН ЯУМАСАМ, БАГЪЛАР ШИҢӘРЛӘР,
БОЛЫНЛЫКЛАР, ЯШЕЛЛЕКЛӘР КИБӘРЛӘР».

КОЯШ ЯҢГЫР БЕЛӘН КҮП КЫЧКЫРЫШКАЧ,
БЕРЕ-БЕРСЕН ЯМАНЛАРГА ТЫРЫШКАЧ,—


ТАТУЛАШТЫ, КИЛЕШТЕЛӘР АХЫРДА
БУ КӨННӘН СҮЗ КӨРӘШТЕРМӘСКӘ БЕР ДӘ.

ШУЛАЙ БЕТТЕ БОЛАРДА СҮЗ ВӘ ТАРТЫШ,
КҮРЕРГӘ БУЛДЫЛАР НӘҮБӘТ БЕЛӘН ЭШ.

КОЯШ ӘЙТТЕ: «КЫЗАМ ҮЗ НӘҮБӘТЕМДӘ,
Ә СИН ЯУ РӘХМӘТЕҢЛӘ НӘҮБӘТЕҢДӘ».

КОЯШ, ЯҢГЫР ӘЛЕ БУ КӨНГӘ ЧАКЛЫ
БОЗЫП ЭШ КЫЙЛМЫЙЛАР БУ ИТТИФАКЪНЫ.




Рәссам ЗӨФӘР ХӘКИМ



Художник ЗУФАР ХАКИМОВ

Габдулла Тукай



ДОЖДЬ И СОЛНЦЕ

СКАЗАЛО СОЛНЦЕ: «БУДУ ВЕК СВЕТИТЬ,
СОВСЕМ НЕ БУДУ С НЕБА УХОДИТЬ».

ОТВЕТИЛ ДОЖДЬ: «Я БУДУ ДЕНЬ ЗА ДНЕМ
ВСЕ ЗАЛИВАТЬ ПОТОКАМИ КРУГОМ».

СКАЗАЛО СОЛНЦЕ: «НО ВЕДЬ ТЫ — ВОДА,
В ГРЯЗЬ ПРЕВРАЩАЕШЬ ЗЕМЛЮ ТЫ ВСЕГДА.

ОДНО ТЫ ЗНАЕШЬ — ЛИТЬ: РУЧЬИ ТЕКУТ,
РАСПУТИЦУ РОЖДАЯ ТАМ И ТУТ.

ХЛЕБА В ПОЛЯХ ГНИЮТ, СКУДЕЕТ ДОЛ,
И МОЛИТСЯ МУЖИК, ЧТОБ ТЫ НЕ ШЕЛ».

А ДОЖДЬ В ОТВЕТ: «ТЫ ОТО ДНЯ КО ДНЮ
ВСЕ ЖАРЧЕ — ХЛЕБ СЖИГАЕШЬ НА КОРНЮ!»

ОТ ГНЕВА СОЛНЦЕ ЗАПЫЛАЛО ЗЛО,
ПЫЛАНЬЕ ВСЕ ГРАНИЦЫ ПЕРЕШЛО.

СКАЗАЛО СОЛНЦЕ: «ОТ МОИХ ЛУЧЕЙ
И ПЛОД, И СВЕТ ЗЕМЛЕ ОБШИРНОЙ ВСЕЙ».

ОТВЕТИЛ ДОЖДЬ: «УЖ ЕСЛИ ТЫ ПЛОДЫ
ПЛОДИШЬ, ТО КАК РАСТИ ИМ БЕЗ ВОДЫ?

ИДТИ НЕ БУДУ, БЛАГУ ПРИНОСЯ,—
ПОВЫСОХНУТ САДЫ И ЗЕЛЕНЬ ВСЯ».

ОНИ ТАК ДОЛГО СПОРИЛИ В ПЫЛУ,
ТАК ДРУГ НА ДРУГА СЫПАЛИ ХУЛУ,

ЧТО ПОД КОНЕЦ РЕШИЛИ СЛОВО ДАТЬ
БЕСПЛОДНЫЙ ЭТОТ СПОР НЕ ПРОДОЛЖАТЬ.

ОНИ РЕШИЛИ ДЕЛО ТАК ВЕСТИ,
ЧТОБ КАЖДЫЙ БЫЛ В ПОЧЕТЕ И В ЧЕСТИ.

ДА БУДЕТ СОЛНЦЕ В СВОЙ ЧЕРЕД ПЫЛАТЬ,
ДОЖДЬ В СВОЙ ЧЕРЕД СВОЙ ДАР НИСПОСЫЛАТЬ!

И ДОЖДЬ И СОЛНЦЕ С ТЕХ ДАЛЕКИХ ПОР
НЕ НАРУШАЮТ ЭТОТ УГОВОР.



Җәүдәт Дәрзаманов

АЛМАЗ

БЕР ИТЕГЕ УҢГА КАРЫЙ,
ИКЕНЧЕСЕ СУЛ ЯККА.
УҢЫН СУЛГА БУТАП КИГӘЧ,
КЫЕНДЫР УЛ АЯККА.

БИЯЛӘЙ ИШЛЕ-СЫҢАРЛЫ,
БҮРЕК КАПЛАГАН КҮЗЕН.
ӘЛЛӘ МАЛАЙ, ӘЛЛӘ КЫЗ УЛ,
ТАНЫП ТА БУЛМЫЙ ҮЗЕН.

ТАНЫМАСА ТАНЫМАСЛАР,
АЛМАЗ СӨЕНӘ ГЕНӘ:
ИНДЕ БҮГЕН ИКЕНЧЕ КӨН
ҮЗЕ КИЕНӘ МЕНӘ!



Рәссам АЛЛА АЙСИНА

Колыбельная

Джавдат Дарзаманов

АЛМАЗ

ПРАВЫЙ САПОГ — НА ЛЕВОЙ НОГЕ,
ЛЕВЫЙ САПОГ — НА ПРАВОЙ.
КАК НЕУДОБНО! МОЖНО ЛИ БЫТЬ
ЭТАКИМ ВОТ РАЗЗЯВОЙ?

ВАРЕЖКИ — ОБЕ — С ОДНОЙ РУКИ,
ШАПКА НА ЛОБ НАДЕТА.
ТО ЛИ ДЕВЧОНКА, ТО ЛЬ МАЛЬЧУГАН, —
И НЕ УЗНАТЬ, КТО ЭТО.

ПУСТЬ НЕ УЗНАТЬ... СМЕЕТСЯ АЛМАЗ
РАДОСТНЫМ СМЕХОМ ВСЕ ЖЕ:
ВОТ УЖЕ ЦЕЛЫХ ДВА ДНЯ, КАК ОН
САМ ОДЕВАТЬСЯ МОЖЕТ.

Перевод
ИГОРЯ ЕЛИСЕЕВА.

Художник АЛЛА АЙСИНА

Тарихи мирас

XIV·XV·XVI·XVII·XVIII·XIX·XX

Шәмгун хан

Шәмгун хан Идел буе Болгар дәүләте тәхетендә 976—997 елларда утыра. Тарихчылар язуына ышансак, бу угланны Икенче Мөэмин хан Дунай буе Болгарыннан алып кайта. Шәмгун угланның яу барышында үтерелгән Питәй каһанның угылы йә оныгы булу ихтималы да бар. Чөнки Икенче Мөэмин хан нәкъ шул дәвердә Дунай буе Болгарына яу йөри. Христиан диненә йөз тота башлаган Питәй каһанны Ислам диненә инандырырга теләгәндер, күрәсең. Иллә безгә мәгълүм булганы шулдыр: Идел буе Болгары Ислам динен рәсми төстә 922 елда кабул итә, ә Дунай буе болгарлары исә христиан динен рәсми рәвештә бары тик 981 елларда гына кабул итәләр. Димәк, Икенче Мөэмин ханның Дунай буе Болгарына яу йөреп, тегеләрне Ислам диненә инандырырга йөрүе хак булса кирәк.

Шәмгун хан ил белән идарә иткәндә үги атасы Икенче Мөэмин хан юлын тота. Әмма, аннан үзгә буларак, тире иләүгә, нигездә һөнәрчеләргә игътибарын арттыра. Нәкъ менә Шәмгун хан тәхеттә утырганда иң затлы иләнгән күннәрне барча шәрык илләрендә дә диярлек «болгари» дип йөртә башлыйлар. Затлы, асыл, балдак аша узардай юка һәм йомшак итеп иләнгән күннәрне кайбер илләрдә бүген дә «болгари» дип йөрүләре мәгълүм.

Шәмгун хан болгар-татар тарихына һөнәрчелеккә аеруча игътибар итүче, күн иләүдәге сәнәгатькә һәм күнгә бизәкләр төшерүгә күп көч салган хан буларак кереп калган.

Сәхифәне язучы
***МӨСӘГЫЙТ ХӘБИБУЛЛИН** әзерләде.*



Рәссам ИЛДАР ӘХМӘТИ

Шамгун хан

Шамгун хан правил Волжской Булгарией в 976—997 годах. Если верить историкам, мальчиком его привез хан Муэмин II из Дунайской Булгарии. Возможно также, что это сын или внук убитого в сражении кагана Питяя. Ведь именно в это время хан Муэмин II ходил войной на Дунайскую Булгарию, желая наказать кагана за то, что он без его согласия принял христианство. Достоверно известно, что Волжская Булгария официально объявила ислам государственной религией в 922 году, тогда как дунайские булгары приняли христианство только в 981 году. В таком случае возможно, что поход хана Муэмина II имел целью обратить дунайских булгар в исламскую веру.

Шамгун хан своим правлением продолжает политику отчима хана Муэмина II. Но, в отличие от него, особое внимание он уделяет развитию кожевенного ремесла. Как раз во время правления Шамгун хана, выделанная в Волжской Булгарии высококачественная кожа получила среди восточных народов название «булгари». Дорогую, тончайшей выделки кожу, которую можно пропустить через колечко, и по сей день в некоторых странах называют «булгари».

Своим особенным вниманием и поддержкой мастеров кожевенного дела, прославивших Волжскую Булгарию своим мастерством высококачественной отделки кожи и даже вышивки на ней изысканных узоров, Шамгун хан остался в истории Волжской Булгарии.

Перевод ***АИДЫ АГАНОВОЙ.***




Художник ИЛДАР АХМАДИЕВ

Әхлакый тәрбия

Каюм Насыйри

Китап • әти • тәрбия



ЕГЕРМЕ АЛТЫНЧЫ ТӘРБИЯ


Бер фәкыйрь бервакытны бик мохтаҗ булып калды. Дустларыннан берсе әйтте: «Фәлән кеше бик бай вә нигъмәт иясе адәмдер, әгәр синең мохтаҗ икәнеңне белсә, шаять шәфкать кыйлыр»,— диде.

Бу фәкыйрь әйтте: «Бәлки шулай булыр иде, әмма мин аны белмәймен»,— диде. Ул кеше әйтте: «Әйдә, мин үзем күрсәтәем аны сиңа»,— диде. Бергә бардылар. Бу фәкыйрь, барып йиткәч, ишегалдында берәүне күрде: иреннәре салынган, күңелсез вә хафа утырыр. Бу фәкыйрь бер сүз әйтмәенчә кайтып китте...

Рәссам ЗАҺИР ХӘКИМ

Каюм Насыри

Книга о воспитании



НАСТАВЛЕНИЕ ДВАДЦАТЬ ШЕСТОЕ

Один бедняк впал в большую нужду. Друг дал ему совет: «Такой-то человек богат. Если он узнает, как ты бедствуешь, то, наверное, поможет тебе». «Может, ты и прав,— ответил бедняк,— но я не знаю этого человека». Друг сказал: «Пойдем, я покажу его тебе». Вот пришли они к дому, во дворе которого увидели невеселого человека. По-видимому, что-то сильно удручало его. Бедняк повернул назад, так и не заговорив с этим человеком, ибо понял, что тот достоин еще большего сострадания...

Художник ЗАГИР ХАКИМОВ

«ИЗУЧАЕМ ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК»

УТЫЗ ДҮРТЕНЧЕ ДӘРЕС

(Тридцать четвертый урок)

1. Әңгәмә.

Татар халык шагыйре Габдулла Тукай турында сөйләшәбез.



— Габдулла Тукай кем ул?

— *Тукай татар халкының бөек улы, шагыйрь, әдәби тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе.*

— Ул кайчан туган?

— *Тукай 1886 елда Татарстанда туган.*

— Ул кайчан үлгән?

— *Тукай 1913 елда 27 яшендә вафат була.*

— Ул нинди әсәрләр язган?

— *Ул шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр язган.*

2. Габдулла Тукай балалар өчен дә матур-матур шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр иҗат иткән. Укыгыз һәм урысчага тәрҗемә итегез.



«Шүрәле»




«Су анасы»



«Карлыгач»




«Кояш һәм ай»



«Бичара куян»



«Кәҗә белән сарык экияте»



«Эш беткәч, уйнарга ярый»




«Бәхетле бала»




«Гали белән кәҗә»



«Кызыклы шәкерт»



«Бала белән күбәләк»



«Фатыйма белән сандугач».

Балалар һәрвакыт хайваннар, кошлар һәм бөҗәкләр белән дус. Рәсемнәрдә кемнәрне күрәсез? Сөйләп бирегез.

СҮЗЛЕК:

халык шагыйре — народный поэт
кояш һәм ай — солнце и луна
сандугач — соловей
шәкерт — ученик медресе
иҗат — творчество
су анасы — водяная, русалка
бичара куян — бедняга заяц
карлыгач — ласточка
күбәләк — бабочка
наследие — мирас

чәчмә әсәрләр — прозаические произведения
шүрәле — лесной дух, леший; персонаж татарских сказок
бәхетле бала — счастливый ребенок
эш беткәч, уйнарга ярый — после работы можно и поиграть

3. Г. Тукайның «Бала белән күбәләк», «Фатыйма белән сандугач», «Кызыклы шәкерт» шигырьләрен рольләргә бүлеп укып чыгыгыз ***(һәр укучы бу шигырьләрдән берничә юлны күңелдән ятлый)*****.**



4. Тукай халык телен бик яраткан. Ул татар теленең иң матур һәм күңелгә якын иң гади үрнәкләрен сайлап алган. Аңарда сүзләр һәм тел чаралары энҗеләр булып ялтырыйлар. Тукайның «Туган тел» шигыре болай башланып китә:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Родной язык — святой язык, отца и матери язык,
Как ты прекрасен! Целый мир в твоем богатстве я постиг!

(Перевод ***С. ЛИПКИНА.****)*

* * *

«Кызыклы шәкерт» шигырен бергәләп тәрҗемә итеп карыйк:

— Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

Рәссам ЗӨФӘР ХӘКИМ ▢ *Художник ЗУФАР ХАКИМОВ*

Ул Р. Моран тәрҗемәсендә болай яңгырый:

— Ну, давай, Акбай, учиться! Сядь, дружок, на хвостик свой!
Смело стой на задних лапках! Чур, не падать, прямо стой!

5. Ягез әле, Г. Тукайның «Гали белән кәҗә» шигырен үзебез урысчага тәрҗемә итеп карыйк:



ГАЛИ БЕЛӘН КӘҖӘ

Безнең Гали бигрәк тату кәҗә белән,
Менә кәҗә карап тора тәрәзәдән.

Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый, сакалын селкетә.

Сүзгә-сүз дә урысчага күчерергә була. Аны урысча шигъри яңгырашка да туры китерәләр:

С козою дружит наш Гали который год,
Он вместе с ней гулять идет на огород.

Свою козу там угощает он травой,
Ну а коза трясет довольно бородой.

*(Перевод **В. ЛУНИНА.**)*

6. Үткәннәрне кабатлау йөзеннән «Кышка бер сүз» шигыреннән әйберләрне һәм күренешләрне белдергән сүзләрне — исемнәрне һәм эш-хәрәкәт сүзләрен — фигыльләрне аерып күрсәтегез.

КЫШКА БЕР СҮЗ



Кит әле син, аксакал кыш! Күр, әнә таудан туры
Тәгәридер ул матур кыз — язның алтын фәйтуны.

Тиз югал, и кыш бабай, син ал да тиз кач карт — башың,
Барыбер, күрсәң, качарсың, язны — гөлләр патшасын!

Бер дә юк ул патшаның мылтык-кылыч, алмаслары,
Һәр ягында аллы-гөлле күбәләктән гаскәре.

ИСЕМНӘР: *аксакал кыш; кыз; яз; алтын фәйтун; кыш бабай; баш; гөлләр патшасы; патша; мылтык-кылыч, алмас; күбәләк; гаскәр.*

ФИГЫЛЬЛӘР: *кит; күр; тәгәридер; югал; ал; кач; качарсың.*

БИРЕМ: *шигырьнең эчтәлеген балаларга аңлатып бирегез, сүзләрне урысчага күчерегез.*

7. Шүрәле, су анасы, Таз, шәкерт, Акбай, карлыгач, сандугач сүзләрен аңлатып бирегез. Г. Тукайның «Бала белән күбәләк», «Гали белән кәҗә» шигырьләрен күңелдән ятлагыз.

*Дәресне филология фәннәре докторы, профессор **ВАХИТ ХАКОВ** алып бара.*




*Урок ведет доктор филологических наук, профессор **ВАХИТ ХАКОВ.***

Рассам ЗӘФӘР ХӘКИМ □ Художник ЗУФАР ХАКИМОВ



Язарга өйрәнәбез!






я я я я

/ / / ооо / / / ооо

Я Я Я Я Я




ял яз язу

яу ява ябалак


Аяз укый. Язилә сөйли

ll ll ооо ооо



в в в в в в

В В В В В В



Василә Вәкил

Вакыт авыл савыт

Равия яза. Сәвия рәсем ясый


вагон вокзал

ваза

в в в



Учимся писать!





ТАПИР



Тапирлар — атларның якын кардәшләре. Бу — чагыштырмача зур булмаган, алгы аякларында дүрт, ә арткыларында өч бармаклы акрын кыймылдаучан хайван. Тапирларның сузынкы өске иренле, кечкенә күзле, үрә торган колаклы башлары озынча һәм тар. Аларның аяклары нык һәм озын, койрыклары кыска.

Җирдә тапирларның ике — азия һәм америка төрләре тереклек итә. Беренчесе күпкә төзрәк һәм камилрәк гәүдәле. Аны икетөсле, яки чуар тапир дип тә йөртәләр. Азия тапирының төп төсе — ачык-кара, тик сырт өлеше генә сорыак. Бу хайванның озынлыгы, 8 сантиметрлы койрыгын да исәпләп, 2,5 метр. Ул Һиндкытайда, шулай ук Суматра һәм Борнео утрауларында да очрый.

Америка тапиры азиянекеннән аз гына кечерәк. Аның озынлыгы 2 метрга җитә. Төсе бертөрле карасу-коңгырт, зур булмаган ялы бар.

Америка тапиры Көньяк Американың көньягында һәм көнчыгышында очрый.

Һәм Азия, һәм Америка тапирлары да кара урманнарда яшәүне кулай күрәләр һәм ачык урыннарга бик сирәк чыгалар. Алар шактый тиз чабалар, әмма тагын да яхшырак йөзәләр һәм чумалар. Бу хайваннарның ишетү һәм ис тою сәләте зур үсеш алган, әмма күрү сәләте зәгыйфьрәк. Тапирның тавышы үзенчәлекле ачы сызгыруны хәтерләтә.

Тапирлар бик киң холыклы, тынычлык яратучы һәм өркәк хайваннар. Хәтта аз гына кыштырдау да аларны кинәт курку (паника) хәленә китерә. Дошманнарыннан тапирлар чабып котылалар һәм бик сирәк очракларда гына, нигездә тешләрен файдаланып, каршы торалар.

Урысчадан
ФИРДӘВЕС ЗАРИФ
тәрҗемәсе.

Рәссам ЗӨФӘР ХӘКИМ



ТАПИР

Тапиры — близкие родственники лошадей. Это сравнительно небольшие, неуклюжие животные с четырьмя пальцами на передних ногах и тремя на задних. У тапиров продолговатая, узкая голова с удлиненной верхней губой, маленькими глазками и стоячими ушами. У них крепкие высокие ноги и короткий хвост.

На земле обитает два вида тапиров — азиатский и американский. Первый вид намного стройнее и совершеннее последнего. Его также называют двухцветным, или чепрачным тапиром. Основной его цвет — чисто-черный и только чепрак серовато-белый. Длина этого животного 2,5 метра, включая 8-сантиметровый хвостик. Водится он в Индокитае, а так же на островах Суматра и Борнео.

Американский тапир — немного меньше азиатского. Его длина составляет 2 метра. Окрашен он в однообразный черно-коричневый цвет и имеет небольшую гриву.

Встречается американский тапир на юге и востоке Южной Америки.

И азиатский, и американский тапиры предпочитают жить в глухих лесах и очень редко выходят на открытые пространства. Бегают они достаточно быстро, но еще лучше плавают и ныряют. У этих животных очень хорошо развит слух и обоняние, но зрение достаточно слабое. Голос тапира напоминает своеобразный резкий свист.

Тапиры очень добродушные, миролюбивые и пугливые животные. Даже легкий шорох приводит их в настоящую панику. От врагов они спасаются бегством и в очень редких случаях обороняются, используя в основном зубы.

Художник ЗУФАР ХАКИМОВ





БЕЛӘБЕЗ, БЕЛӘБЕЗ!

(Корея халык әкияте)

Яшәгән ди, булган ди ир белән хатын. Начар кешеләр булмасалар да, алар башкаларны тыңларга яратмаганнар. Күршеләре нәрсә турында сөйли башласалар да, һәрвакыт бүлдереп: «Беләбез, беләбез!» — дип кычкырганнар.

Бервакыт алар йорты яныннан кулына халат тоткан кеше узып бара икән.

Ир кеше аннан:

— Нигә халатыңны кимисең? — дип сорый.

Юлаучы:

— Әгәр халатны киеп, бер төймәгә эләктерсәң, җирдән бер метр биеклеккә күтәреләсең, ике төймәгә — агачлардан биегрәк, ә инде өчкә икән — бөтенләй күккә очасың,— дип җавап биргән.

Ир, ничек кире кайтуны сорыйсы урынга:

— Беләм, беләм! — дип кычкырган.

Халатны эләктереп, өстенә кигән һәм бөтен төймәләргә төймәләп, күккә очкан.

Ә хатын аның артыннан йөгерә һәм кычкырып, мактана икән:

— Карагыз, карагыз, һаман биеккәрәк менә! Минем ирем оча!

Елгага барып төшкәнче, шулай йөгергән ул. Чөнки хатын аяк астына түгел, күккә генә караган.

Шулай килеп чыккан инде: ир күктә эзсез югалган, ә хатын — елгада.

Әйтүләренчә, ир кошка, ә хатын балыкка әверелгән. Бу андый кешеләр өчен бик яхшы әле.

Әгәр дә син, шушы ир һәм хатын кебек, үзеңә әйткәнне ахырга кадәр тыңламасаң, синең белән тагын да күңелсезрәк хәлләр килеп чыгарга мөмкин.

Урысчадан
ФИРДӘВЕС ЗАРИФ тәрҗемәсе.

Рәссам ИЛДУС ӘҖЕМ







ЗНАЕМ, ЗНАЕМ!

(Корейская сказка)

Жили-были муж и жена. Люди они были неплохие, но не любили слушать других. Только соседи начнут о чем-нибудь рассказывать — всегда они прервут и кричат: «Знаем, знаем!»

Однажды проходил мимо их дома человек. У него в руках был халат.

Вот муж и спрашивает его:

— Почему ты не надеваешь халат?

Прохожий отвечает:

— Если надеть халат и застегнуть на одну пуговицу, то поднимешься в воздух на метр от земли, если на две пуговицы — выше деревьев, если на три — совсем в небо улетишь.

Муж, вместо того чтобы спросить, как назад возвратиться, закричал:

— Знаю, знаю!

Схватил халат, надел, застегнул на все пуговицы и полетел в небо.

А жена за ним по земле бежит и кричит, хвастается:

— Смотрите, смотрите, все вверх! Мой муж летит!

Так она бежала, пока не упала в речку. Ведь она все смотрела в небо, а не себе под ноги.

Вот и получилось, что муж бесследно пропал в небе, а жена — в реке.

Говорят, он превратился в птицу, а она в рыбу. И это, конечно, еще очень хорошо для таких людей, как они.

Ведь если ты, как эти муж и жена, не будешь дослушивать до конца то, что тебе говорят, с тобой могут случиться еще худшие неприятности.

Художник ИЛДУС АЗИМОВ



ТӨЛКЕ МИККЕЛЬ ҺӘМ АЮ БАМСЕ

(Норвегия әкияте)

Төлке Миккель һәм аю Бамсе күптәннән үзара дошманлашып яшәгәннәр. Аю төлкедән күпкә көчлерәк булса да, төлкене һич кенә дә җиңә алмаган, чөнки тапкыррак һәрвакыт өстен чыга бит. Тик бер генә мәртәбә карт Бамсе төлкене дә юләр хәлдә калдырган. Халык арасында сөйләнгән шундый көлкеле вакыйгаларны тыңлап карагыз әле.

«Чыршы тамырын ташла — төлке койрыгын эләктер!»

Бервакыт җәй көне аю Бамсе калкулыкта утыра һәм кояшта изрәп, черем итә икән. Шул вакытта урманнан төлке Миккель кача-поса чыгып килә. Аюны күрүгә, болай уйлап куя: «Йокымсырыйсыңмы, бабакай? Ах син, ялкау! Ярый, менә хәзер мин сине кызык итим әле».

Ул урманда өч тычкан тотып ала да, аларны аюның борын төбендәге түмгәккә куеп, шыпырт кына тагын да якынрак килә һәм аюның колагына:

— Бух, бух! Уян, Бамсе! Пер-укчы тау артында! — дип кычкыра.

Шулай кычкыра да — үзе урманга кереп сыза!

(Дәвамы бар.)

Урысчадан
ФИРДӘВЕС ЗАРИФ *тәрҗемәсе.*

Рәссам ЗАҺИР ХӘКИМ





ЛИС МИККЕЛЬ И МЕДВЕДЬ БАМСЕ

(Норвежская сказка)

Издавна враждовали меж собою лис Миккель и медведь Бамсе. И хоть медведь намного сильнее лиса, а никак ему с Миккелем не совладать было, потому что верх всегда тот берет, у кого смекалки больше. Только один раз так вышло, что и старый Бамсе лиса в дураках оставил. Вот послушайте одну из потешных историй, какие о них в народе рассказывают.

«Бросай еловый корень — хватай лисий хвост!»

Сидел однажды летом медведь Бамсе на пригорке да и задремал на солнышке. А тут лис Миккель из лесу крадется. Увидел он медведя и думает: «Дремлешь, дедуля? Ах ты, лежебока этакий! Ну погоди, сейчас я с тобой шутку сыграю».


Поймал он в лесу трех мышей, положил их на пенек под носом у медведя, а сам подкрался к нему тихонько да как гаркнет над самым ухом:

— Бух, бух! Проснись, Бамсе! Пер-стрелок за горою!

Покричал он так — а сам деру в лес!

(Продолжение следует.)

Художник ЗАГИР ХАКИМОВ





Индекс 73954



Рәссам *СВЕТЛАНА ИБРАГИМОВА* • Художник *СВЕТЛАНА ИБРАГИМОВА*

Цена договорная